ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# "Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 өлешендә "шәхси" сүзен төшереп калдырырга;

2) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" ордены белән шулай ук, дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан тыш, оешмалар һәм аларның бүлекчәләре (алга таба – оешмалар) бүләкләнергә мөмкин.";

3) 8 статьяда:
а) $2^{1}$ өлештә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;
б) 3 өлештә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;
в) 4 өлештә "орденын" сүзеннән соң "гражданнар тарафыннан" сүзләрен өстәргә;
г) түбәндәге эчтәлекле 6 – 7 өлешләр өстәргә:
"6. "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" ордены белән оешмалар икътисадны, мәдәниятне, фәнне, мәгарифне, сәламәтлек саклауны, сәнгатьне, спортны һәм хезмәт эшчәнлегенең башка өлкәләрен үстерүдәге, илнең оборона куәтен һәм хокук тәртибен саклауны ныгытудагы аерым казанышлары өчен бүләкләнәләр.
7. Бүләкләнгән оешмаларның байрагы булса, орден оешма карары белән байракка тагылырга мөмкин. Байракка тагылган очракта орден, байракның өске читеннән 15 сантиметр һәм байрак таягыннан 10 сантиметр ара калдырып,

тукыманың уң ягына, оешмаларның СССР орденнары булганда, алардан соң урнаштырыла.";

4) $8^1$ статьяның 2 өлешендә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;

5) $8^2$ статьяның 2 өлешендә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;

6) 9 статьяның 2 өлешендә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;

7) 10 статьяның 2 өлешендә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;

8) 11 статьяның 6 өлешендә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;

9) 12 статьяның 2 өлешендә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;

10) 13 статьяның 39 пунктында "Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары" сүзләрен "Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр органнары Атказанган" сүзләренә алмаштырырга;

11) 15 статьяда:
а) 1 өлештә:
беренче җөмләдә "затларга" сүзен "гражданнарга" сүзенә алмаштырырга;
икенче җөмләдә "затларга" сүзен "гражданнарга" сүзенә алмаштырырга;
б) 2 өлештә "затлар" сүзен "гражданнар" сүзенә алмаштырырга;

12) 16 статьяда:
а) 1 өлештә җөмлә башына "Гражданнарны" сүзен өстәргә;
б) 2 өлештә:
беренче абзацта "кандидатуралар" сүзен "гражданнар кандидатуралары" сүзләренә алмаштырырга;
икенче абзацта ике урында тиешле килештәге "зат" сүзен тиешле килештәге "граждан" сүзенә алмаштырырга;
в) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:
"6. Оешмаларны бүләкләү турындагы үтенечнамәләр эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә идарә итү функцияләрен (функциональ җайга салуны) башкаручы республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан языла.";

13) 17 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктта “гражданның” сүзен “гражданның һәм оешманың” сүзләренә, “затларга” сүзен “гражданнарга яисә оешмаларга” сүзләренә алмаштырырга;

14) 21 статьяда:

а) 2 пунктта “зат” сүзен “граждан” сүзенә, “күрсәтелгән затлардан” сүзләрен “каралган очрактан” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

“4) оешма үзгәртеп корылганда яисә бетерелгәндә.”;

15) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

“4. Оешмаларны “Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен” ордены белән бүләкләү елга бер мәртәбә Татарстан Республикасы Президенты указы белән башкарыла һәм, кагыйдә буларак, Яз һәм Хезмәт бәйрәменә (1 майга) туры китерелә.”;

16) 23 статьяда:

а) 3 өлештә “мактаулы исеме бирелгән зат” сүзләрен “мактаулы исеме бирелгән граждан” сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта җөмләнең калган өлешләре үзгәрми;

б) 4 өлештә “мактаулы исеме бирелгән зат” сүзләрен “мактаулы исеме бирелгән граждан” сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта җөмләнең калган өлешләре үзгәрми;

17) 25 статьяда:

а) 1 өлешнең беренче җөмләсендә җөмлә башына “Гражданга” сүзен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Бүләкләнгән оешмага дәүләт бүләге, кагыйдә буларак, бүләкләнгән оешма коллективы катнашында оешманың җитәкчесенә яисә вәкаләт бирелгән затка тапшырыла.”;

18) 26 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

“3. Бүләкләү турында документ бүләкләнгән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме үзгәрүгә яисә бүләкләнгән оешманың исеме үзгәрүгә бәйле рәвештә алмаштырылмый.”;

19) 27 статьяның 2 өлешендә “бүләкләнүчеләр” сүзен “бүләкләнгән гражданнар” сүзләренә алмаштырырга;

20) 28 статьяда:

а) 1 өлештә “затлар” сүзен “гражданнар” сүзенә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган оешмаларның җитәкчеләре Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен кую урыннарын

билгелиләр, бу урыннар аларның саклануышын һәм оешма хезмәткәрләренең алар белән таныша алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.";

21) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $31^{1}$ статья өстәргә:

"$31^{1}$ статья. **Бүләкләнгән оешма үзгәртеп корылган яисә бетерелгән очракта Татарстан Республикасы дәүләт бүләген тапшырып калдыру тәртибе**

1. Бүләкләнгән оешма үзгәртеп корылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге әлеге оешманың хокукый дәвамчысына кала.

2. Бүләкләнгән оешма бетерелгән очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә кире кайтарылырга тиеш яисә, Татарстан Республикасы Президенты карарында билгеләнгәнчә, саклау һәм экспонат итеп куллану өчен дәүләт музеена тапшырылырга мөмкин.";

22) 32 статьяның 2 өлешендә "затка" сүзен "гражданга яисә оешмага" сүзләренә алмаштырырга;

23) 33 статьяда:

а) 1 өлештә җөмлә башына "Гражданнарны" сүзен өстәргә;

б) 3 өлештә "затныкы" сүзен "гражданныкы" сүзенә алмаштырырга;

24) 34 статьяның 2 өлешендә "затның" сүзен "гражданның" сүзенә алмаштырырга;

25) 37 статьяда:

а) исемдә "затларга" сүзен "гражданнарга" сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә "затларга" сүзен "гражданнарга" сүзенә алмаштырырга;

26) 39 статьяның 3 өлешендә "затларга" сүзен "гражданнарга" сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 18 марты
№ 11-ТРЗ